**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ КЫЯЗЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

12 нчы декабрь 2019 ел № 15

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге Башкарма комитетының « 2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын раслау турында» 2018 нче елның 20 нче февраленнән 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 20 нче февралендәге 2нче номерлы карары белән расланган 2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплексы үстерү программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1.4 пунктның 3 абзацында «муниципаль заказны формалаштыру» сүзләрен «муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны оештыру» сүзләренә алмаштырырга; «максатчан программалар» сүзләрен «муниципаль программалар»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Иске Кыязлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Аксубай муниципаль районының http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru/ рәсми сайтында закон белән билгеләнгән вакытта бастырып чыгарырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Иске Кыязлы авыл җирлеге

Башкарма комитетыны җитәкчесе Г.Г.Дәүләтшин